| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

____14.06.2022____________ г. Казань № под-1048/22

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган «Татарстан Республикасы мәгарифен үстерү институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә 2022 елда Татарстан Республикасында «Яндекс Академиясе Лицее» белем бирү проектын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатлар өчен субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен ачыклый торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатлар өчен субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында»» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 178 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның «Яндекс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять генераль

директоры А.А.Шульгин белән 2017 елның 11 ноябрь ПР-328 номерлы очрашу беркетмәсе нигезендә, б о е р а м:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган «Татарстан Республикасы мәгарифен үстерү институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә 2022 елда Татарстан Республикасында «Яндекс Академиясе Лицее» белем бирү проектын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен расларга.

2. Мәгълүмати технологияләр һәм куркынычсызлык бүлегенә (И.Н.Сарманов) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вакытта дәүләт теркәвен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары М.З.Закировага йөкләргә.

Министр И.Г.Һадиуллин

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән расланган
от 14.06.2022 № под-1048/22

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган «Татарстан Республикасы мәгарифен үстерү институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә 2022 елда Татарстан Республикасында «Яндекс Академиясе Лицее» белем бирү проектын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган «Татарстан Республикасы мәгарифен үстерү институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә 2022 елда Татарстан Республикасында «Яндекс Академиясе Лицее» белем бирү проектын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү кагыйдәләрен ачыклый (алга таба - Тәртип).

2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

«Яндекс академиясе лицее» мәгариф проекты (алга таба – Проект) – гомуми белем бирү оешмаларының 8 – 10 сыйныфларында белем алучылар өчен программалаштыру буенча бушлай курслар;

Гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Учреждениегә карата гамәлгә куючының функциясен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы;

субсидия – тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм билгеләнгән тәртиптә Гамәлгә куючыга расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, Учреждениягә төп боерык бирүче һәм акчалар алучы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Гамәлгә куючыга бирелә торган, 2022 елда проектны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бирелә торган субсидия.

Әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3. Субсидия Учреждениягә 2022 елда проектны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә.

## II бүлек. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

4. Субсидия алу максатларында Учреждение Гамәлгә куючы адресына субсидия алу өчен гариза (алга таба – Гариза) бирә, ул үз эченә түбәндәге документларны ала:

Учреждениенең ирекле рәвештә рәсмиләштерелгән субсидия алуга язма мөрәҗәгате;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән максатларга субсидия бирү кирәклеген нигезләүне, Чараларны үткәрер өчен чыгымнарның башлангыч сметасын да үз эченә алган аңлатма язу;

салым органының салым һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмавын раслаучы Гариза бирелә торган айның беренче числосына бирелгән белешмә;

Учреждениене үзгәртеп оештыру яки бетерү чараларын гамәлгә ашыруга, авария хәлендәге (гадәттән тыш) ситуацияне булдырмау, авария (гадәттән тыш) килеп чыккан очракта һәм торгызу эшләрен башкару очракларыннан, законлы көченә кергән суд актлары буенча бурычны үтәтү документлары буенча түләүләрдән, һәм шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә, Учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кайтару буенча срогы чыккан бурычы булмавы турында Гариза бирелә торган айның беренче числосына бирелгән, Учреждение җитәкчесе һәм баш бухгалтеры кул куйган, Учреждение мөһере белән беркетелгән, белешмә;

Тапшырыла торган документлар ачык басылган булырга тиеш. Учреждение җитәкчесенең язма мөрәҗәгате Учреждениенең мөһере (булган очракта) белән беркетелергә һәм шуңа вәкаләтле затның имзасы белән яисә Учреждение җитәкчесенең үз кулы белән таныкланырга тиеш. Субсидия алуга документлар әзерләү буенча барлык чыгымнарын Учреждение үзе алып бара.

Учреждение үзе тәкъдим иткән Гаризаны чакыртып алырга һәм аны кабат тәкъдим итәргә хокуклы.

Документлар һәм Гариза электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасын кулланып бирелгән очракта, алар электрон рәвештә Учреждение җитәкчесенең яисә Учреждение җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручының электрон имзасы белән имзаланырга тиеш.

5. Гамәлгә куючы, әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә тәкъдим ителгән Гаризаны, теркәгән көннән алып 10 (ун) эш көне эчендә, карый, андагы белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм субсидия бирү турында йә аны бирүдән баш тарту турында Учреждениегә хәбәр итә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

Учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

6. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә Гамәлгә куючы һәм Учреждение субсидияләр бирү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типлаштырылган рәвеш нигезендә килешү (алга таба - килешү) төзи, анда түбәндәге нигезләмәләр керә:

Чараларның исемен күрсәтеп, субсидия бирү максатлары;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планы;

субсидия күләме;

субсидияне күчерү сроклары (графигы);

субсидия финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында, килешүне үтәү турында;

килешү белән билгеләнгән субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм вакытлары;

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымта нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында хисап бирү тәртибе һәм вакытлары,

килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Гамәлгә куючыга субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта;

Гамәлгә куючы карары буенча бер яклы тәртиптә килешүне вакытыннан алда туктату өчен нигез булып торучы шарталар, шул исәптән:

Учреждениене үзгәртеп оештыру (кушу рәвешендә үзгәртеп корудан тыш) яисә бетерү,

әлеге Тәртиптә һәм (яисә) килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозу;

Учреждение тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзүне тыю.

Кирәк булганда Гамәлгә куючы һәм Учреждение килешүгә өстәмә килешү яисә килешүне өзү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типлаштырылган рәвешләр нигезендә өстәмә килешү төзи.

7. Бирелә торган субсидиянең күләме ($C$) Учредитель тарафыннан, әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә бирелә торган Гаризада чагылдырылган Учреждениенең ихтыяҗын исәпкә алып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = \sum_{i=1}^{5} З_i,$$

кайда:

$З_1$ – Россия Федерациясенең хезмәт һәм салым законнары нигезендә Учреждениенең локаль норматив актларында каралган кызыксындыру һәм башка түләүләр нигезендә вазыйфаи окладларны исәпкә алып билгеләнә торган ярдәмче

программаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган Учреждение хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фондын булдыруга юнәлтелгән чыгымнар;

$З_2$ – хезмәт законнары һәм Россия Федерациясенең иминият кертемнәре турындагы законнары нигезендә билгеләнә торган мәҗбүри социаль иминләштерү буенча кертемнәр түләүгә, хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә һәм учреждение хезмәткәрләренә башка түләүләргә дигән чыгымнар;

$З_3$ – учреждение персоналына, Россия Федерациясе норматив актларын һәм гамәлгә куючы карарларын исәпкә алып, Учреждение ихтыяҗыннан чыгып төзелә торган хезмәткә түләү фондыннан тыш, башка түләүләргә чыгымнар;

$З_4$ – тиңдәш товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән җитештерүче-оештыручыларның бәяләре, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең рәсми сайтларын да кертеп, чагыштырма базар бәяләре (базарны анализлау) ысулы белән формалаштырылган, Учреждение ихтыяҗы нигезендәге элемтә хезмәтләренә, мөлкәттән файдалануга, мөлкәтне карап тотуга һәм башка эшләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә дигән чыгымнар,

$З_5$ –Учреждениенең финанс булмаган активларын арттыруга китерә торган чыгымнар, төп чараларның, матди булмаган активларның, җитештерелмәгән активларның, Татарстан Республикасы норматив актлары һәм Учреждениенең локаль норматив актлары белән җайга салына торган матди запасларның бәяләрен арттыручы чыгымнарны үз эченә ала.

8. Гариза бирелә торган айның беренче числосына Учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Учреждениенең салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк;

Учреждениенең үзгәртеп оештыру яки бетерү чараларын гамәлгә ашыруга, авария хәлендәге (гадәттән тыш) ситуацияне булдырмау, авария (гадәттән тыш) килеп чыккан очракта һәм торгызу эшләрен башкару очракларыннан, законлы көченә кергән суд актлары буенча бурычны үтәтү документлары буенча түләүләрдән, һәм шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә, Учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кайтару буенча срогы чыккан бурычы юк;

Учреждение әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатка Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акчалар алмый.

9. Субсидия бирү нәтиҗәсе – Әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән Чараның нәтиҗәләренең күрсәткечләренә (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларына) ирешү.

10. Гамәлгә куючы субсидияне Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә ачылган Учреждениенең исәп-хисап счетларына тулы күләмдә, килешүдә каралган субсидияне күчерү графигы буенча күчерә.

## III бүлек. Хисап тапшыруга таләпләр

11. Учреждение Гамәлгә куючыга әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы җиденче һәм тугызынчы абзацлары нигезендә түбәндәге срокларда хисаплылык тапшыра:

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган өч эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисап;

ай саен, хисап аеннан соң килүче өч эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендә, раслый торган документларын да кертеп, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турындагы хисап;

хисап елының соңгы аеның 25 көненнән дә соңга калмыйча, Гамәлгә куючы раслаган форма буенча, Чараларны гамәлгә ашыру турында белешмәләре булган килешүнең үтәлеше турындагы хисап.

Тапшырыла торган хисап һәм теркәлә торган документлар ачык басылырга тиеш. Учреждениенең мөһере белән беркетелгән һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланган төзәтмәләрдән тыш төзәтмәләр кертү рөхсәт ителми.

## IV бүлек. Субсидия бирү максатларының, шартларының үтәлешен һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны контрольдә тоту тәртибе

12. Гамәлгә куючы Учреждениягә Субсидия бирү максатларының һәм шартларының үтәлешен тикшереп тора.

13. Учреждение субсидия алу өчен яисә субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырган, әлеге Тәртип нигезендә субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен, шулай ук субсидияне тоту максатларын, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирмәгән өчен һәм (яисә) субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшырмаган, субсидияне максатчан билгеләнеш буенча файдаланмаган, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада билгеләнгән күрсәткечләргә (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларына) ирешмәгән өчен җаваплы.

Учреждениене җаваплылык чараларын кулланудан азат итү өчен нигез булып Учреждениегә тиешле йөкләмәләрне үтәүгә комачаулаучы җиңеп булмый торган көчләрне раслаган документ тора.

14. Учредитель һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча ачыкланган субсидия биргәндә билгеләнгән максатлар һәм шартлар үтәлмәгән очракта, субсидия Учреждение тарафыннан Гамәлгә куючының тиешле таләбен алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

Әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре түбәнәю очрагында, субсидия Учреждение Гамәлгә куючының тиешле таләбен алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

15. Әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару

срогы бозылганда, Гамәлгә куючы, күрсәтелгән срок тәмамланган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә, күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджетына мәҗбүри тәртиптә Россия Федерациясе законнары нигезендә түләттерү чараларын күрә.

16. Әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешүгә дип бирелгән, агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидия акчаларының калган өлешләре Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

Гамәлгә куючы, файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлешләре, шулай ук Учреждениенең күрсәтелгән йөкләмәләре булуын һәм күләмен (физик затларга түләү йөкләмәләреннән тыш) раслаучы документлар (документларның күчермәләре) булуы турында Учреждениенең агымдагы елның 20 эш көне дәвамында, субсидия бирү елыннан соңгы ел дәвамында юнәлдерелгән (алга таба – субсидияләрнең калган өлешләре буенча Учреждение мөрәҗәгате) мөрәҗәгате нигезендә, агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидия акчаларының калган өлешләрен әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешер өчен файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул итә.

Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешүгә дип бирелгән, агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидия акчаларының калган өлешләрен җибәрү ихтыяҗы булу турындагы Учреждение мөрәҗәгатен алган мизгелдән алып 5 эш көне эчендә карар кабул итә.

17. Гамәлгә куючының әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешүгә дип бирелгән, агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидия акчаларының калган өлешләрен җибәрү ихтыяҗы булу турындагы карары нигезендә, әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешүгә финанс белән тәэмин итү өчен юнәлдерелгән чыгымнарны агымдагы финанс елында файдаланылырга мөмкин.

18. Агымдагы финанс тәэминаты чыганагы булып субсидияләр булган, элек башкарылган түләүләрне кире кайтарудан килгән кертемнәр булган очракта, Гамәлгә куючы, әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешү өчен, алардан файдалану турында карар кабул итә. Карар, Учреждениенең агымдагы финанс тәэминаты чыганагы булып субсидияләр булып торган, элек башкарылган түләүләрне кире кайтарудан килгән кертемнәр булган йөкләмәләрен һәм күрсәтелгән йөкләмәләрнең күләмен (физик затлар тарафыннан түләү йөкләмәләреннән тыш) раслаучы документларын (документларның күчермәләре) үз эченә керткән, субсидия бирү елыннан соң килүче елның 20 эш көне дәвамында җибәрелгән Учреждение мөрәҗәгате нигезендә кабул ителә (алга таба – Учреждениенең элек башкарылган түләүләрне кире кайтарудан килгән акчалар буенча мөрәҗәгате).

Учредитель принимает решение об использовании в текущем финансовом году поступлений от возврата ранее произведенных Учреждением выплат, источником финансового обеспечения которых является субсидия, для достижения целей, установленных пунктом 3 настоящего Порядка, в течение 5 рабочих дней с момента обращения Учреждения по средствам от возврата ранее произведенных выплат.

Гамәлгә куючы агымдагы финанс елында, Учреждение тарафыннан финанс

белән тәэмин итү чыганагы субсидия булып торган, элек башкарылган һәм кире кайтарылган түләүләрдән торган кертемнәрне, әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен, Учреждениенең элек башкарылган түләүләрне кире кайтарудан килгән акчалар буенча мөрәҗәгат иткән вакыттан алып 5 эш көне эчендә, файдалану турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган «Татарстан Республикасы мәгарифен үстерү институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә 2022 елда Татарстан Республикасында «Яндекс Академиясе Лицее» белем бирү проектын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенең 1 нче кушымтасы

Нәтиҗәләрнең билгеләре
(ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)

| п/п | Нәтиҗәнең атамасы (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы), үлчәү берәмлеге | Нәтиҗәнең әһәмияте (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) |
|---|---|---|
| | | 2022 ел |
| 1. | «Python телендә программалаштыру нигезләре» мәгариф программасында белем алучылар саны, кеше | 700 дән дә ким түгел |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган «Татарстан Республикасы мәгарифен үстерү институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә 2022 елда Татарстан Республикасында «Яндекс Академиясе Лицее» белем бирү проектын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенең 2 нче кушымтасы

Форма

Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында
20___елның «__» ______ хисап

Учреждениенең исеме ___________________________________
Хисап итү чоры: квартал саен
Үлчәү бердәмлеге: сум (икенче унарлы билгегә кадәр төгәллек белән)

| | Сумма | |
|---|---|---|
| | хисап итү чорында | ел башыннан арта барган нәтиҗә белән |
| *1* | *2* | *3* |
| Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия чаралары килде | | |
| Субсидия чаралары (касса чыгымнары) тотылды | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылды | | |
| Хисап чоры ахырына субсидиянең калган өлеше | | |
| шул исәптән: кире кайтарылырга тиеш | | |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган «Татарстан Республикасы мәгарифен үстерү институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә 2022 елда Татарстан Республикасында «Яндекс Академиясе Лицее» белем бирү проектын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенең
3 нче кушымтасы

Форма

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында
20___елның «__» ______ хисап

Учреждениенең исеме _____________________________________________
Хисап итү чоры: ай саен

| № п/п | Нәтиҗәнең атамасы | 20____ елга планлаштырылган сан | Хисап датасына нәтиҗәгә ирешелгән сан | План үтәлешенең проценты | Тайпылышлар сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|
| *1* | *2* | *3* | *4* | *5* | *6* |
| | | | | | |

Гамәлгә куючы

_______/ Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)/

М.П

Учреждение

_______/ Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)/
М.П

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган «Татарстан Республикасы мәгарифен үстерү институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә 2022 елда Татарстан Республикасында «Яндекс Академиясе Лицее» белем бирү проектын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенең
4 нче кушымтасы

форма

Субсидия (контроль нокталар) бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планын гамәлгә ашыру турында хисап
1 _________ 20__ ел

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | КОДЛАР |
| | | Дата | |
| | | Ирекле реестр буенча | |
| Алучының исеме | ________________ | ИНН | |
| Федераль бюджет чараларын баш бүлүчесенең исеме | ________________<br>(Министрлык, Агентлык, Хезмәт күрсәтү, башка орган (оешма) | Ирекле реестр буенча | |
| Дәүләт программасының (федераль проектның) структур элементы исеме | ________________ | БК буенча | |
| Субсидия исеме | ________________ | БК буенча | |

Килешү номе
Килешү дата

Документ төре

(беренчел - "0", төгәлләштерелгән - "1", "2", "3", "...

| Субсидия бирү нәтиҗәләре, контроль нокталар | | | Үлчәү бердәмлеге | | Сан кыйммәте | | | Нәтиҗәгә ирешү срогы (кк.аа.ееее.) | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Исеме | коды | төре | Исеме | ОКЕИ буенча код | планлаштырылган | фактик | фаразланган | планлаштырылган | факти (фаразла |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Субсидия бирү нәтиҗәсе | | | | | | | | | |
| хисап чорының контроль нокталары | х | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |
| план чорының контроль нокталары | х | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |
| Субсидия бирү нәтиҗәсе | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| хисап чорының контроль нокталары | х | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |
| план чорының контроль нокталары | х | | | | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Алучының җитәкчесе (вәкаләтле заты) | ____________ (вазыйфасы) | ____________ (имза) | ____________ (имзаның аңлатмасы) |
| Башкаручы | ____________ (вазыйфасы) | ____________ (фамилиясе, инициаллары) | ____________ (телефон) |

"__" _________ 20__ г.